


ЧАЛЛЫДА НИЧЕК СӨЯЛӘР?

Чаллыда ничек сөяләр?
Әллә ни үзгә түгел.
Шул ук кояш, шул йолдызлар,
Шул ук ай бизи күген.
Сүзләре дә гади сүзләр,—
Бабайлардан калган сүз.
Эзләре дә таныш эзләр,
Әйтерсең, без салган эз.
Шаярта монда егетләр:
— Алтын безнең бәябез,
Күрешергә барасы бар,
Шуңа дип юл җәябез.
Ап-ак өйләр.
Япь-яшь кызлар.
Кызлары сүзгә зирәк:
— Кичләрен бергә йөрергә
Иркен урамнар кирәк.
Анда урам... Монда урам...
Кыр кырыкка бүленә.
Яңа туган урамнарда
Гашыйклар мул күренә.
Ә ерακта, әйтерсең лә,
Нәкъ әкият дөньясы —
Көмеш тасма булып сузыла
Автозавод бинасы.
Яратам, дип кем дә әйтә,
Исбат итү кыен эш.

Эш тә сорый, хис тә сорый
Җир күрмәгән түзелеш.
Шуңа кызлар егетләргә
Сүз ката иртә-кичен:
— Безгә үз җырыбыз кирәк,
Җырлап туй итәр өчен.
Шуларны күреп йөргәндә
Күңелләргә дәрт тула.
Чын-чынлап Чаллыча сөю
Менә ул ничек була.

# Чаллыда ничек сөяләр?

Чаллыда ничек сөяләр?
Әллә ни үзгә түгел.
Шул ук кояш, шул йолдызлар,
Шул ук ай бизи күген.
Сүзләре дә гади сүзләр, -
Бабайлардан калган сүз.
Эзләре дә таныш эзләр,
Әйтерсең, без салган эз.
Шаярта монда егетләр:
-Алтын безнең бәябез,
Күрешергә барасы бар,
Шуңа дип юл җәябез.
Ап-ак өйләр.
Япь-яшь кызлар.
Кызлары сүзгә зирәк:
-Кичләрен бергә йөрергә
Иркен урамнар кирәк.

Анда урам...Мона урам...

Кыр кырыкка бүленә.

Яңа туган урамнарда

Гашыйклар мул күренә.

Ә еракта әйтерсең лә,

Нәкъ әкият дөньясы-

Көмеш тасма булып сузыла

Автозавод бинасы.

Яратам, дип кем дә әйтә,

Исбат итү кыен эш.

Эш тә сорый, хис тә сорый

Җир күрмәгән төзелеш.

Шуңа кызлар егетләргә

Сүз ката иртә-кичен:

-Безгә үз җырыбыз кирәк,

Җырлап туй итәр өчен.

Шуларны күреп йөргәндә

Күңелләргә дәрт тула.

Чын-чынлап Чаллыча сөю

Менә ул ничек була.

**Хәниф Хөснуллин**